Казан (Идел буе) федераль университеты газетасы

# DARELFӨNYN
УНИВЕРСИТЕТ

12+

№ 29 (42)

25 октябрь 2012 ел

## • Универ хәлләре

**18 ОКТЯБРЬ** көнне КФУда «Туган телләрне саклау һәм үстерү» халыкара фәнни-гамәли форумы нигезендә **«ТАТАРЛАРГА ТЫЛМАЧЛАР КИРӘК» РЕСПУБЛИКА ОЛИМПИАДАСЫНЫҢ ЙОМГАКЛАУ ТУРЫ ҮТКӘРЕЛДЕ**. Чара ике этапта узды. Беренчесе дистанцион рәвештә булды. Анда республикабызның төрле мәктәп-гимназияләреннән 600дән артык укучы катнышты, икенче турга шуларның 40ы гына үтте. Гран-прига Актаныштан Айдар Шәйхин ия булды.

• • • •

**19-20 ОКТЯБРЬ** көннәрендә фәлсәфә факультетының конфликтология кафедрасы «Иҗтимагый партнерлык – институт һәм тәҗрибәләрнең заманча трансформациясе» темасына багышланган **«КОНФЛИКТЛАРНЫ ТИКШЕРҮ МЕТОДОЛОГИЯСЕ» ХАЛЫКАРА ФӘННИ ФОРУМЫН УЗДЫРДЫ**. Өч сессия кысаларында үткән фикер алышу нәтиҗәсендә, катнашучылар иҗтимагый партнерлыкның институт һәм тәҗрибәләрне гамәлгә ашыру өлкәсендә алга таба да уртак эшчәнлек алып барырга сүз куештылар.

• • • •

**22-23 ОКТЯБРЬДӘ** Казан университеты ректоры **ИЛШАТ ГАФУРОВ** җитәкчелегендәге КФУ делегациясе Санкт-Петербург шәһәрендә үткәрелгән **«РОССИЯ ШӘҺӘРЛӘРЕНДӘ ҺӘМ ӨЛКӘЛӘРЕНДӘ СТРАТЕГИК ПЛАНЛАШТЫРУ: ИНТЕГРАЦИЯ ПОТЕНЦИАЛЫ» ДИП ИСЕМЛӘНГӘН XI РОССИЯКҮЛӘМ ФОРУМЫНДА КАТНАШТЫ**. Делегация составында икътисади һәм стратегик үсеш буенча проректор Марат Сафиуллин, Идарә итү һәм территориаль үсеш институты директоры Наилә Баһаветдинова, Дәүләт һәм муниципаль идарә югары мәктәбенең директоры Лилия Нургатина бар иде. Ректорыбызга форумда актив катнашканы, аны әзерләү һәм үткәрүгә керткән зур өлеше өчен «Леонтьев үзәге» дип исемләнгән Халыкара иҗтимагый-икътисади тикшеренү үзәгенең генераль директоры, форумның оештыру комитеты төркеменең җитәкчесе И.А.Карелин рәхмәт хаты тапшырды.

• • • •

**22 ОКТЯБРЬ** көнне КФУ ректоры Илшат Гафуров катнашында «Россия шәһәрләре һәм өлкәләрендә стратегик планлаштыру: интеграция потенциалы» дип исемләнгән XI Россиякүләм форумы кысаларында **«ӨЛКӘЛӘРНЕҢ СТРАТЕГИК ҮСЕШ ЮЛЫНДА ФЕДЕРАЛЬ УНИВЕРСИТЕТЛАРНЫҢ РОЛЕ» ИСЕМЛЕ ТҮГӘРӘК ӨСТӘЛ УЗДЫ**. Чарада «Федераль округның үсешендә федераль университет нинди урын алып торырга тиеш?», Иң абруйлы халыкара университетлар исемлегенә керергә дигән максат куйган федераль университетларга дәүләт ярдәм итәргә тиешме?», «Халыкара рейтингның кайсы Россиянең адекват шартларына туры килә?», «Безгә милли рейтинг кирәкме?» кебек сорауларга җаваплар эзләнде.

• • • •

**22 ОКТЯБРЬДӘ** Казан федераль университетында «Магнитлы резонанс һәм аның кушымталарының актуаль проблемалары» дип исемләнгән **XV ХАЛЫКАРА ЯШЬЛӘР ФӘННИ МӘКТӘБЕ ҮЗ ЭШЧӘНЛЕГЕН БАШЛАП ҖИБӘРДЕ**. Чарада Россия галимнәре белән берргәттән чит ил галимнәре дә лекция укыды, катнашучылар докладлар белән чыгыш ясады. Яңа ЭПР һәм ЯМР спектрометрларда мастер-класслар да уздырылды. Мәктәпнең эшчәнлеге 26 октябрьгә кадәр дәвам итә.

• • • •

**24 ОКТЯБРЬ** көнне А.М.Бутлеров исемендәге Химия институтының Бутлеров аудиториясендә «Фарма 2020» максатчан федераль программа кысаларында ТР Клиник фармакологлары җәмгыяте белән берлектә **ФАРМАКОЛОГИЯ БУЕНЧА ФӘННИ СЕМИНАР УЗДЫРЫЛДЫ**.

*kpfu.ru сайты материаллары файдаланылды.*



Руслан Гыйниятов фотосы

# Кулымда икеләтә диплом!

**Алинә САДЫЙКОВА,**
хәбәрче

Университетыбызның чит ил уку йортлары белән хезмәттәшлек итеп, студентлар алышу тәҗрибәсен кулланганы һәркемгә билгеле, ә икеләтә диплом турында ишеткәнегез булмагандыр әле. Гаҗәп тә түгел, әлеге программа нибары дүрт ел гына эшли һәм аның «Беренче карлыгачлары» дипломнарын 24 октябрьдә генә кулларына алды.

КФУ – SUNY икеләтә дипломнар буенча мәгариф үзәген Икътисад һәм финанс институты (КФУ исеменнән) һәм Нью-Йорк штаты дәүләт университетының SUNY Canton технология колледжы (Нью-Йорк штаты дәүләт университеты исеменнән) тәшкил итә. Ул Financial Services (финанс хезмәт күрсәтүләре) белгечлеге буенча BBA Degree дип исемләнгән эшлекле идарә итүнең бакалавр программасын гамәлгә ашыра. Әлеге проект Икътисад һәм финанс институтында укытыла торган фундаменталь фәннәр һәм менеджмент белән эшлекле бәйләнешнең америка стилен берләштерә. Укуларын тәмамлаган студентлар SUNY Canton белән Икътисад һәм финанс институтына караган икеләтә бакалавр дәрәҗәсен ала.

Бу программа буенча беренче чыгарылышка диплом тапшыру тантанасы университетыбызның төп бинасында урнашкан Тарих музеенда узды. КФУ ректоры Илшат Гафуров чарага килгән кунакларны сәламләп, шундый төр проектларның әһәмияте турында әйтте: «Мондый программалар, һичшиксез, уку йортыбызны тәмамлаучыларның конкурентлык сәләтен арттыра. Әлеге проектның үзенчәлеге дә шунда: ул университетыбызда формалашып килә торган «икеләтә диплом»нар, «икеләтә яклаулар» (кандидатлык диссертациясе һәм PhD) яңа системасына туры килә».

Ректорыбызның тәбрикләү сүзләреннән соң, SUNY Canton халыкара программаларының директоры Марела Фиакко һәм SUNY Canton президент штабы җитәкчесе Райан Патрик Дуэль студентларга җылы теләкләрен житкерде. «Бу дипломнарны алыр өчен, сез бик озын һәм авыр юл уздыгыз. Шундый зур сынау алдында югалып калмыйча, аны җиренә җиткереп эшләгәнегез өчен сезгә рәхмәт әйтәм. Белемнәрегезне дөрес һәм лаеклы файдаланыгыз», – диде Марела Фиакко.

Диплом алган студентлар фикер һәм теләкләрен остазларына рус һәм инглиз телендә җиткерде.

«Беренче карлыгачлар» бармак белән генә санарлык. Шулай да, хикмәт санда түгел, ә сыйфатта бит!

## • Бәйрәм

# Беренче курсларның каймагы УНИКСта җыелды!

**Зилә ФӘСХИЕВА,**
хәбәрче

Кичә УНИКС концертлар залында беренче курслар көненә багышланган чараның гала-концерты үтте. Уйлап-уйлап куям да, тагын бер кат шуңа инанам: бүгенге беренче курслар, әле биш-алты ел элек укыганнардан күпкә аерыла, бик күпкә...



Әмир Фазлыйәхметов фотосы

Гала-концерт дәвамында уйларым дәлилләнә генә барды. Һәр чыгыш үзенчәлекле, бер-берсен кабатламый торган иде. Исегезгә төшерәбез:сентябрь-октябрьдәвамындажюри рәисе һәр институттан университетыбызның иң-иң талантлы булачак йолдызларын барлаган иде. Менә алар: УНИКС сәхнәсендә КФУ беренче курсларының каймагы!

Югары курс студентлары арасында, беренче сессияне тапшырганнан соң гына син чып-чын студент буласың, дигән гыйбарә яшәп килә. Ә гала-концертта катнашучыларны студент исеменә бүген үк лаек дияр идем. Чөнки мондый креатив, җыр-моңга, уен-көлкегә бөтенләй яңа төсмер биреп, чып-чын бәйрәм оештыручыларга ничек инде син әле студент түгел дияргә була?

Кич шактый суык булуына карамастан беренчеләребезгә көч-куәт өстәп торырга иптәшләре, дус-ишләре шактый җыелды. Ә гала-концерт ахырында һәркемнең йөзендә нур, уңай кичерешләр чагылуын күрергә мөмкин иде! Заман белән бергә атлаган, мавыктыргыч бәйрәм бүләк иткәннәре өчен һәммәсенә дә рәхмәт сүзләре ирештерәсе килә! Һәрдаим актив, максатчан, үз дигәнегезгә ирешә торган булыгыз. Афәрин, беренчеләр!

● Әй, язмыш!

# Егерме бер роза кыйссасы

**Алинә САДЫЙКОВА,**
хәбәрче

Яшь чак – юләр чак, диләр. Егет белән кыз булып йөргән чакларда бу юләрлек тагын да көчле була. Күптән түгел генә танышларым арасында булган бер вакыйга фикеремне тагын да ныгытып куйды.

Илнур белән Лилия күптәннән таныш. Язмыш аларны очраштыру турында бик озак баш ватып тормыйча, гадәти юлны гына сайлый. Мәктәпне тәмамлаганнан соң, бер уку йортына керәләр, бер төркемгә эләгәләр. Бер-берсенә карата илаһи хис туа барганны аңлар өчен, егеткә дә, кызга да шактый вакыт кирәк була.

Илнур бар игътибарын Лилиясенә бирә: гел кайгыртып, аның өчен борчылып тора. Лилия үз бәхетенә үзе ышанмыйча, мәхәббәттән күкнең җиденче катында очып йөри. Һәрвакыт назлы аралашу, саф мәхәббәт хисләренә күнеккән яшь җилкенчәкләр кайбер сынауларга әзер булмый әле. Төрле аңлашылмаучанлыклар, борчу-мәшәкатьләр аларны да урап узмый.

...Көз фасылы күп кешедә күңел төшенкелеге тудыра. Илнур белән Лилиягә дә бу халәт кучкәндер, күрәмсең, көзнең салкын һәм ачы җилләре кинәт кенә аларга да кагылып үтә. Шалтыратулар кими, очрашулар сирәгәя, аралар суына... Мондый халәттә калу – алар өчен беренче тапкыр гына. Берәүләр шушындый очракта кул кушырып, үзләренең мәхәббәтләре өчен көрәшүне дәвам итми, ә берәүләр изге хисләрен көчләреннән килгәнчә саклап калырга тырыша. «Көчләреннән килгәнчә» дигәнне һәрбер кеше үзенчә аңлый, әлбәттә. Үз ысулларын куллана. Ә Илнур исә бу мәсьәләгә бик кызыклы гына борылыш биреп җибәрә.

Үпкәләшкәннәренә ике-өч көн үткәч, Илнур ясаган хатасын аңлап, Лилияне югалтасы килмәгәненә төшенә. Хәзер гафу үтенергә, янәдән кызның күңелен яуларга кирәк бит. Гадәти көнне дә буш кул белән килмәгән егет бу юлы чәчкәләрнең дә иң-иңнәрен сайлап ала: дистәләгән гөлчәчәкләрдән зур букет тоттыргач, курчак буйлы гына Лилия бу матурлык арасыннан күренми дә. Әмма Лилия тиз генә бирешми... Нәрсәләр генә алып килсә дә, кызны үзенә кире кайтара алмаячагын аңлаган егет көннәрдән бер көнне Лилиянең күзләрен бәйли дә, машинага утыртып аны бер билгесез тарафка алып китә. Вакыйгаларның шундый борылыш алуына әзер булмаган кызның алга таба ни буласын бик тә беләсе килә, шунлыктан ул егеткә каршы бармый.

Илнур Лилиянең күзләрен чишеп җибәргәч, кыз үзенең ниндидер бина эчендә басып торуын күрә. Беренче карашка шомлы серлелек, аңлашылмаучанлык бар, бераздан кызның күңелен тынычлык биләп ала: аңа рәхәт булып китә, күңеленә илаһи тынычлык урнаша. Шулай да, кыз ахырга кадәр үзенең кайда икәнлеген аңлый алмыйча басып тора, бары тик ерактан башына түбәтәй кигән, бераз сакал җибәргән ир-атны күргәч кенә үзенең мәчеттә икәнлегенә төшенә. Сорау тулы күзләрен егетенә юнәлдергәч, Илнур муллага: «Безнең араларыбыз бозылмасын өчен, берәр дога укыгыз, өшкерегез әле», – ди. Егеттән мондый адымны көтмәгәнлектән, Лилия инде ни дияргә дә белми, аптырап кала. Хәер, мулла абзый өчен дә бу гадәти күренеш булмый. Мондый рәвештә сорагач, дин әһеле яшьләргә юк дия алмый инде. Егетнең үтенечен кире какмый. Кемгә ничектер, әмма бу вакыйга мине елмаерга мәҗбүр итте, гаҗәпләнү катыш соклану хисе тудырды. Миңа калса, Илнур сыман проблемаларга креатив якын килгән кешеләр күбрәк булса, тормышыбыз да кызыграк һәм үзенчәлеклерәк булыр иде.



Алия Галимуллина фотосы

● Сәламәтлек

# Дөрес киенә беләбезме?

**Зилә ФӘСХИЕВА,**
хәбәрче

Җәмәгать транспортында барганда, беркөнне күңелсез генә хәлгә юлыктым. Кондукторга биргән акчасы җиргә төшеп киткәч, яшь кыз иелеп шуны барларга кереште. Читтән караган кешегә тәнен кысып торган чалбарның аска шуып китүен күрү бер дә күңелле булмагандыр. Гәрчә ул кызны, гомумән, белмәсәм дә, аның өчен бик оялдым. Ни дисәң дә, хатын-кызларга билдән түбән «зауженный», «заниженный»лар, кысып торган киемнәр бер дә килешми шул...

Дөреслектә исә, тәнгә сыланган киемнең зыяны турында күпләр белеп тә бетерми. Кысып торган чалбарлар кан әйләнешен боза, шул ук вакытта веналарда кан туктауга, аларның киңәюенә кадәр барып җитәргә мөмкин. Чалбар гына түгел, майка-футболка кебек артык тәнне буа торган киемнәрнең дә файдасыннан зыяны күбрәк, чөнки алар күкрәк читлегенә басым ясап, сулыш органнарына, сөт бизләренә тискәре йогынты ясый. Тагын шунысын да искә алырга кирәк: артык үтә күренмәле, кыска һәм тәнгә сыланып торган киемнәр әхлаксызлык, әдәпсезлек, тыйнаксызлыкны күрсәтә. Икенчедән, бик күпләр модалы дип санаган мондый типтагы киемнәр – күптән инде зәвыксызлык билгесе.

Чалбар-итәкләрнең билдән шактый аска төшеп торуы шулай ук яхшы түгел. Бу бөерләрнең суынуына китерә. Ә бөерләр суынса, организм да үзенең җавап реакциясен бирәчәк: чәчләр коела, тешләрдә кариес башлана, еш кына умыртка баганасы авырулары да газаплавы бар. Иң куркынычы: кызлар киләчәктә әни булу бәхетеннән мәхрүм ителергә мөмкин.

Кысып торган джинсылар көнбатышта махсус төзүчеләр өчен тектерелгән була. Бүген ул – бездә киң кулланышта йөри торган киемнәрнең берсе. Миңа калса, киемнең иң уңайлысы һәм матуры – тәнебезне каплап торганы, һәрнәрсәдән саклаганы, сәламәтлегебезгә зыян салмаганыдыр! Үз сәламәтлегебез – үзебезнең кулларда!

● Әдәп-әхлак

# Тыйнаклыкның үз урыны

**Гөлчирә ИМАНКОЛЫЙ,**
татар филологиясе бүлеге студенты

«Тыйнаклык – ярты бәхет», – дип өйрәтә әти-әниләребез, ләкин һәр очракта да түгел. Бу иң элек үз-үзеңне матур итеп тоту, әдәп саклау дигән сүз.

Дөрестән дә, кая гына карама, татар кешесе тыйнак булып иялэнгән инде. Өстәл артында утырганда да, кешеләр арасында да, автобуста, китапханә, кибеттәме – кая гына гына булмасын, татар кешесе үзенә кирәген дә ала алмыйча, ниндидер сәбәпләр аркасында тиешле кеше белән аңлаша алмыйча китеп тә барырга мөмкин.

Юкка гына сүзне тыйнаклыктан башламадым. Язмамның нигезенә татарларның әллә тыйнаклыкка, әллә башка нәрсәгә бәйле рәвештә кирәк сүзләрен әйтә, фикерләрен җиткерә алмавында. Мондый кешеләр исәбенә, берсүзсез, мин дә керәм.

Шәһәр шау-шуында олы мәшәкатьләр белән янып-көеп йөрүчеләр исәбендә без хәзер. Кем эшли, кем эшләп укый, кем укый һәм тагын укый. Гомумән, әллә никадәр уй-мәшәкать. Студент елларының да иң авыр чорына аяк бастык. Әле курс эше, әле конференция, әле реферат, әле әдәби әсәр укырга, әле контроль эшкә әзерләнергә. Ни кызганыч, театр-концертларга да җай чыкканда түгел, ә кушканда гына йөри башладык. Әлбәттә, өй эше күп дип аклану дөрес түгел, әмма өлгереп булмый. Шулай беркөнне



төркемебез белән Каюм Насыйри музеена барырга җай чыкты.

Ике катлы искиткеч матур музей-йортны күреп гаҗәпкә калдык. Экскурсия алып баручы ханым музейның икенче катындагы заллар белән таныштыра башлаганчы болай диде: «Килгән кунакларыбыз соравы буенча экскурсияне рус телендә алып барырбыз инде». Әлбәттә, бу җөмләдән соң минем дә, төркемдәшләремнең дә күзләрендә сораулы караш туды.

Шулай итеп экскурсия башланды. Без икенче каттагы ике зал белән танышып чыккач, килгән кунаклар китте. Алар инде безгә кадәр беренче каттагы залда йөргән булган. Ә беренче каттагы экспонатлар белән безне татар телендә таныштырдылар.

Гаҗәпләнерлек тә! Төркемебездә без 19 студент. Музейга килгән «кунаклар» – дүртәү. Шул дүрт кеше өчен музейда рус телендә экскурсия алып барылды. Мөселман-татар кешеләре булдылар, ахры, чөнки хатын-кызлары яулык ябынган иде. Үзләре татар галиме Каюм Насыйри музеена килгән, бер дә татарча аңламыйлар микәнни дип уйлап куйдым. Әлбәттә, гыйлемне нинди телдә алуның әһәмияте юк: кем нинди телне белә, аңлый, шул телдә белем ала. Әмма сүз хөрмәт төшенчәсе турында бара, минемчә. Телгә ихтирам, бөек галимнең якты истәлегенә хөрмәт, башка милләт вәкилләренә игътибар турында аларга да уйларга кирәк булгандыр.

Безнең канга сеңгән: әгәр дә син булган җәмәгать урыннарында башка телдә сөйләшүче милләт вәкилләре күбрәк икән, без – татарлар – берничек тә ана телебездә сөйли алмыйбыз. Гәрчә янында аңлаучылар булса да. Әлбәттә, күпләрнең башында сорау туар: ни өчен татар телендә сөйләгез дип сорамадыгыз соң, дип. Һаман да шул «тыйнаклык», «оялу» инде. Әлеге ике төшенчә, шәхсән минем өчен дә, моңа кадәр гел юлдаш булып килделәр. «Әмма кирәк чакта үз сүзеңне әйтә белергә кирәк, һәр очракта да дәшми калу килешми.» – дип гаиләдә өйрәтсәләр дә, бу юлы да сүз әйтеп булмады. Кемдер үз фикереңне әйтү ызгышуга китерә дияр. Һич алай түгел! Әйтә белеп әйтсәң, дәлилли белсәң, берәү белән дә сүзгә килмәссең.

Димәк, көнләшүнең ак һәм кара төстәгеләре булган кебек, оялуның да «кирәк булганы» һәм «кирәк булмаганы» бар. Оялып, ә бәлки куркып әйтми калу гадәтләрен бетерә башларга вакыттыр. Ике дәүләт теле булган республикада яшибез, ләбаса, ә татар телендә сөйләүне таләп итәргә оялабыз. Әлбәттә, иң беренче эш итеп, үз телебездә үзебез сөйләшергә өйрәник, аннан соң бүтәннәргә дә мөрәҗәгать итә алырбыз. «Милләт һәм телебез бетү куркынычы астында», – дигән фикерләрне тыңлыйбыз да борчылган булабыз. Һич алай куркырга кирәкми: әгәр үзебез сөйләшә алабыз икән, нигә бетсен ул?! Һәркем үз мәнфәгатьләрен генә кайгыртып яшәргә омтылган заманда телне дә үзебез кадерләгәндә генә, бу аңлашылмаучанлыклар бетәр, минемчә.

«Тыйнаклык – ярты бәхет» булса, бәхетнең тагын бер өлеше – үз фикереңне кирәкле вакытта, кирәкле урында һәм кирәкле кешегә җиткерә дә белүдәдер.

● Хикмәтле сүз

- Алтыда белгән ана телең алтмышта онытылмас.
- Ананың балага биргән иң зур бүләге – тел.
- Ана теле бер булыр.
- Әдәп башы – тел.
- Иле барның теле бар.
- Инсафлының теле саф.
- Иң татлы тел – туган тел, анам сөйләп торган тел.
- Кешенең теле аңа дан да китерә ала, хурлык та китерә ала.
- Сөйдергән дә тел, биздергән дә тел.
- Тел белән аңлата алмаганны таяк белән аңлата алмассың.
- Тел дигән дәрья бар, төбендә энҗе-мәрҗән бар,
  Белгәннәр чумып алыр, белмәгәннәр коры калыр.
- Теле барлар – халык булган,
  Теле юклар – балык булган.
- Теле барның юлы бар.
- Тел юата да, елата да.
- Туган телне кадерләгән халык кадерле булыр.
- Туган тел үзем өчен, башка тел көнем өчен.
- Телең белән узма, белемең белән уз.
- Телең белән фикер йөртмә, миең белән фикер йөрт.
- Бәхетле буласының – теле татлы.
- Дөньяда иң татлы нәрсә дә – тел, иң ачы нәрсә дә – тел.
- Телең ни әйтсә, колагың шуны ишетер.
- Яхшы тел еланны оядан чыгарыр,
  Яман тел адәмне иманнан чыгарыр.
- Озын тел гомерне кыскартыр.
- Җил капкада җил тормас, тишек авызда сүз тормас.
- Акыллы телсез надан телледән артык.
- Һәр илнең ачкычы тел, телен белгән ил ачар.

• Әдәби Ат

# Сыерчыклар кайта безгә

**Нәфисә АТАДЖАНОВА,**
Физика институты студенты

*(юмореска)*

Мин – язга гашыйк кеше. Яз айларында табигать сүз белән генә әйтеп бетереп булмаган гүзәллеккә күмелә! Мин аны инде ноябрь айларыннан ук көтә башлыйм...

Шулай бервакыт башка бер уй килде. Сыерчык оясы ясарга! Күп уйланып тормадым – эшкә тотындым. Иң беренче эш итеп такта табарга кирәк иде. Менә хәзер уйга баттым инде... Һммм, каян алырга соң аны? Шулвакыт яраткан укытучыларымның сүзләре искә төште: «Ут күршеләр һәрвакыт ярдәм итәр», – ди иде алар. Күршекәйләрем ягына карап-карап тордым да иң матур, иң ялтырап торган бер-ике койма тактасын куптарып та алдым. Әле ярый файдалы киңәш бирергә укытучылар бар!

Такталарны кочаклап, «остаханәмә» – утын сараена кереп киттем. Төзелеш материалларын әзерләп куйдым да пычкыны тартып җибәрдем... Кадак кадаклаганда, биш бармагым да алма кадәрле булгач, эшне берүзем башкарып чыгара алмаячагыма инандым. Күп тә үтмәде, чүкеч тавышын ишетеп, абыкаем йөгереп чыкты...

– Тагын ни майтарасың инде син, җен кызы?

– Менә, күрүеңчә, яраткан кошчыкларыма оя ясыйм! – дидем мактанып.

– Кайчаннан сыерчык ярата башладың соң әле, синең аны күргәнең дә юк бит!

– Нишләп булмасын, дәреслекләрдә рәсемнәре күп бит аларның! Ясашсаң, чынбарлыкта да күрермен...

– Ә такта каян алдың?

Уйга баттым...

– Күрше абзый инде өченче тапкыр коймасын ямый, әле күз җиткәнгә дә җиде генә көн, – дип уфтанып алды абый. Аннан соң такталарны алды да эшемне дәвам итте. Һәрвакыттагыча, абый кадаклады, ә мин аны мактый-мактый карап тордым. Ничек тә булса ярдәм итәргә кирәк бит инде!

Ниһаять, бар да әзер! Оямны ныгытып тоттым да өй янында үсеп утырган алмагач янына юнәлдем. Анда элегрәк ясаган өч җимлек эленеп тора иде... Нигә өчәү дип сорыйсызмы? Аларны ясаганда, абый да шул ук сорауларны биргән иде. Беренчесе – песнәкләр, икенчесе – чыпчыклар, ә өченчесе чәүкә ише башка кошлар өчен иде аның.

– Кая эләбез моны? – дип сорады абый.

– Алмагачка инде! – дидем мин, белдекле кыяфәт белән.

Ни өчендер абый юкә агачына менеп китте, алмагачка авыр булыр дип уйлагандыр.

– Шундый матур килеп чыкты бу оя, әйдә тагын берне ясыйбыз, – дидем дә күршеләр ягына таба борылдым. Такта кирәк бит инде!

– Тагын койма җимерергә барасыңмы?! А ну, марш өйгә! – дип, абыйның бер генә әйтүе булды, мин комета тизлеге белән өйгә кереп тә сыздым!

...Сыерчыклар кайтканчы, мин көн саен ул оядан чыпчыкларны куып йөрдем.

Ниһаять, сагынып-саргаеп көткән кошчыкларым «курорт»тан – җылы яклардан очып кайтты. Бер сыерчык гаиләсе кайту белән ояма хуҗа булырга да өлгерде. Шундый сөендем ки, сөенечемнән башым күккә тия язды! Әгәр ачыксалар дип, юкә агачына да бер җимлек ясап элдем.

Борчылмагыз, бу юлы күршекәйләрнең койма тактасына кагылмадым, абый үзе каяндыр табып бирде.



Шулай итеп, беренче теләгемне чынга ашыргач, мин, бәхетле кызый, апрель аена эшләрне планлаштыра башладым...

***

**Гали САФИН**

*Сыерчык оясы ясыйм*
*Рәшәткәләрне алып.*
*«Күрше хакы – Алла хакы»,–*
*дип сөйли безнең халык!*

*Күрше абый чыгып бара*
*Колакны алды борып.*
*Үз-үземә вәгъдә бирдем*
*Йөрмәскә карак булып!*

• Кети-мети

*Сыйныф җитәкчесе яңа укучыдан сорый:*
*– Синең кем белән утырасың килә: малай беләнме,кыз беләнме?*
*– Миңа барыбер,– ди укучы. – Иң мөһиме хатасыз гына яза торган булсын!*

***

*– Әти, утны кабыз әле...*
*– Нигә?*
*– Бер бармагым авырта. Кайсысы икәнен күрәсем килә.*

***

*Татар егете бер кыз артыннан йөгерә:*
*– Чибәркәй! Чибәркәй! Туктагыз әле!*
*– Әйе, нәрсә?*
*– Автобуста сез кулчатырыгызны онытып калдырмадыгызмы?!*
*– Ой,чынлап та! Мин онытгым!*
*– Алайса автобус артыннан йөгерегез, ул әле ерак китмәде.*

***

*– Әти, син дә безнең мәктәптә укыган идеңме?*
*– Әйе, улым. Синең кебек 20 ел элек мин дә шунда укыдым.*
*– Әйтәм аны бер көнне укытучы: «Синең кебек надан баланы инде 20 ел очратканым юк иде», - дип сүкте.*

***

*Сез кызларны нечкә күңелле,йомшак дисез. Ә сезнең аларның машина ишеген япканын күргәнегез бармы? Нечкә күңелле,имеш!*

***

*Студент дискәтүктә бер кыз белән бии. Вальс әйләнгән җиреннән егет кинәт авып китә.*
*– Су китерегез, су! – дип кычкыра бичара кыз.*
*Идәннән зәгыйфь тавыш ишетелә:*
*– Һәм бер телем ипи.*




• Спорт

# Баскетболчы юристлар

**Динара ЗИННӘТОВА,**
хәбәрче

Баскетбол – күп еллар дәвамында Университетыбызның иң алдынгы, мавыктыргыч спорт төре. КФУның «УНИКС» спорт комплексында үтә торган баскетбол матчларында тамашачылар, җанатарлар һәрвакыт күп. Бу көннәрдә генә «Беренче курс студентлары спартакиадасы» тәмамланды. 18 октябрь көнне баскетбол буенча ир-егетләр арасында узган финал матчларында да халык шактый иде. Студентлар үз факультетлары, институтлары өчен ихластан җан атты.



Өченче урын өчен Геология һәм кара алтын-газ технологияләре институтының «Геолог» командасы белән Көнчыгышны өйрәнү һәм халыкара бәйләнешләр институтының «Восток» командасы көч сынашты. Матчның башында ук «Восток» алга чыкты, беренче өлешнең алтынчы минутында исәп 7:0 иде. «Геолог» тиз арада көндәшләрен куып җитте. Шулай да матч ахырына 23:21 белән барыбер көнчыгышны өйрәнүчеләр җиңеп чыкты.

Финал матчында Юридик факультетның «Юрист» командасы Икътисад һәм финанс институтының «Экономист» командасы белән көч сынашты. Исәпне «Экономист» уенчысы Руслан Зарытов ачып җибәрде. Беренче өлештән соң, кем җиңеп чыгачагын һич кенә дә белеп булмый иде әле. Командалар уен дәвамында бар көчләреннән көрәшеп, өстенлек әле бер, әле икенче команда ягына авышып торды. Беренче өлеш тәмамлануга 9 секунд калганда уен тигезләште: таблода 10:10 иде. Икенче өлештә хокук белгечләре көч-куәтләрен тулысынча күрсәтте. Нәтиҗәдә, көндәшләренә 4 кенә очко биреп, «Юрист» 40:14 исәбе белән җиңү яулады.

КФУның яңа буын студентлары сынатмады, матчларда яхшы, югары сыйфатлы баскетбол күрсәттеләр. Җиңүне кем яулауга карамастан, спорт залыннан чыгып килүче барлык тамашачы һәм җанатарларның йөзләрендә күтәренке рух, дәрт, яшьлек энергиясе чагыла иде.

DARELFӨNYN УНИВЕРСИТЕТ
Тираж 1000
Газета бушлай таратыла

Баш мөхәррир - Илдар Азат улы Кәримов
Мөхәррир - Рифат Гали улы Сәлахов
Иҗат коллективы: Д.Р.Әхмәтова, А.Ю.Садыйкова, Д.Р.Зиннәтова, З.Ф.Фәсхиева
Биткә салу һәм дизайн буенча белгеч - Г.З.Камалиева

Газетаны гамәлгә куючы – Казан (Идел буе) федераль университеты
Редакция һәм нәшрият адресы: 420021, Казан ш., Профессор Нужин ур., 1/37 йорт, 318 каб.
Хәбәрләшү өчен телефон: 233-70-04.
Электрон почта: darelfonyn@mail.ru Сайт: kpfu.ru

Газета Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә 2012 елның 13 мартында ПИ № ТУ 16-00696 нчы таныклык белән теркәлде.

Бастырылуга кул кую вакыты: график буенча – 16.00, кул куелды – 16.00
«Карти» ҖЧҖ типографиясендә басылды, Казан ш., Восстание ур., 60 й.